КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 31 октябрь г.Казань № 892

«2025 – 2030 елларга Татарстан Республикасында экспорт эшчәнлеген үстерү» төбәк программасын раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән «2025 - 2030 елларга Татарстан Республикасында экспорт эшчәнлеген үстерү» төбәк программасын расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 ел, 31 октябрь, 892 нче карары белән расланды

# «2025 – 2030 елларга Татарстан Республикасында экспорт эшчәнлеген үстерү» төбәк программасы

## «2025 – 2030 елларга Татарстан Республикасында экспорт эшчәнлеген үстерү» төбәк программасы паспорты

### I. Төп нигезләмәләр

| | |
|---|---|
| Программа исеме | «2025 - 2030 елларга Татарстан Республикасында экспорт эшчәнлеген үстерү» төбәк программасы (алга таба - экспортны үстерү төбәк программасы) |
| Экспортны үстерү төбәк программасын башлау һәм тәмамлау сроклары | 01.01.2025 – 31.12.2030 |
| Экспортны үстерү төбәк программасының җаваплы координаторы | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы |
| Татарстан Республикасы дәүләт программалары (ярдәмче программалар / төбәк программалары) һәм төбәк проектлары белән бәйләнеш | «2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисади үстерү стратегиясен раслау турында» 2015 елның 17 июнендәге 40-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (2019 елның 5 апрелендәге 31-ТРЗ номерлы, 2019 елның 25 декабрендәге 112-ТРЗ номрлы Татарстан Республикасы законнары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);<br>Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 08 апрель, 235 нче карары;<br>Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карары;<br>Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2030 елга кадәр Татарстан Республикасында тышкы икътисадый эшчәнлекне үстерү өчен уңайлы шартлар тәэмин итү стратегиясен раслау турында» 2023 ел, 28 декабрь, 1701 нче карары;<br>Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы вәкиллекләре эшчәнлеген индикатив бәяләү турында» 2024 ел, 24 декабрь, 1188 нче карары;<br>Татарстан Республикасы Туризм буенча дәүләт комитетының 2022 елның 16 февралендәге 18 номерлы «2021 – 2030 еллар чорына Татарстан Республикасында туризмны үстерү стратегиясен раслау турында» |

| | |
|---|---|
| | боерыгы;<br>«Татарстан Республикасында халыкара кооперация һәм экспортны үстерүнең системалы чаралары» төбәк проекты;<br>«Кече һәм урта эшмәкәрлек һәм шәхси эшмәкәрлек инициативасын хуплау (Татарстан Республикасы (Татарстан))» төбәк проекты;<br>«Хезмәт җитештерүчәнлеге» төбәк проекты |

## II. Экспорт үстерүнең чакырулары һәм бурычлары

| Т/с | Чакыру формулировкасы | Бурыч исеме |
|---|---|---|
| 1. | 2023 ел күрсәткече белән чагыштырганда 2030 елга чимал булмаган, энергия булмаган товарлар экспорты күләмен кимендә өчтән ике өлешкә арттыру максатында югары конкурентлы продукция экспорты булдыру һәм киңәйтү ихтыяҗы, агросәнәгать комплексы (алга таба – АСК) продукциясе экспорты күләмен 2021 ел белән чагыштырганда 2030 елга 1,5 тапкыр арттыру, гамәлдәге ясалма тышкы сәүдә чикләүләре шартларында | 1. Татарстан Республикасында институциональ экспорт мохитен камилләштерү.<br>2. Дус илләрнең чит ил базарларында катнашуны киңәйтү, сәнәгать кооперациясен киңәйтү.<br>3. Экспорт эшчәнлегенең уңайлылыгын һәм нәтиҗәлелеген тәэмин итүче транспорт-логистика инфраструктурасын формалаштыру.<br>4. Экспортчыларның продукциясен дус илләр базарларына чыгару өчен яңа механизмнар булдыру һәм булганнарын куллану.<br>5. Дус илләр белән тотрыклы партнерлык системасын үстерү |

## III. Экспортны үстерүнең төбәк программасының максаты һәм күрсәткечләре

| Т/с | Күрсәткеч исеме | Күрсәткечнең төп мәгънәсе | | Чоры, елы | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | әһәмият | датасы | 2025 | 2026 | 2027 | 2028 | 2029 | 2030 |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
| Максат: 2030 елга чимал булмаган, энергия булмаган товарлар экспорты үсешен 2023 ел дәрәҗәсенә карата өчтән ике өлешкә арттыру | | | | | | | | | |
| 1. | Төп күрсәткеч: чимал булмаган, энергияг булмаган экспортның реаль үсеше, 2023 елга процентларда | 100 | 31.12.2023 | 100,5 | 104,5 | 113,6 | 131,5 | 147,6 | 167 |
| 2. | Төп күрсәткеч: сәнәгать тармаклары товарлары экспорты күләме (номиналь бәяләрдә), миллион АКШ доллары | 2 216,7 | 31.12.2023 | 2 227,8 | 2 316,5 | 2 518,2 | 2 915,0 | 3 271,8 | 3 701,9 |
| 3. | Төп күрсәткеч: АСК продукциясе экспорты күләме (номиналь бәяләрдә), миллион АКШ доллары | 457,6 | 31.12.2023 | 466,8 | 482,0 | 501,2 | 534,3 | 716,4 | 898,6 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 4. | Өстәмә күрсәткеч: чимал булмаган, энергия булмаган экспорт күләме (номиналь бәяләрдә), миллион АКШ доллары | 2 741,0 | 31.12.2023 | 2 694,6 | 2 798,5 | 3 019,4 | 3 449,3 | 3 988,2 | 4 600,5 |
| 5. | Өстәмә күрсәткеч: кече һәм урта эшкуарлык субъектлары булган экспортерлар саны, берәмлек | 2 287 | 31.12.2023 | 1 900 | 1 910 | 1 920 | 1 930 | 1 940 | 1 950 |
| 6. | Өстәмә күрсәткеч: кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының чимал булмаган, энергия булмаган экспорты күләме, миллион АКШ доллары | 689,0 | 31.12.2023 | 690,4 | 691,1 | 691,8 | 692,5 | 693,1 | 693,8 |
| 7. | Өстәмә күрсәткеч: Татарстан Республикасы экспортлый торган илләр саны, берәмлек | 109 | 31.12.2023 | 115 | 118 | 121 | 124 | 127 | 130 |
| 8. | Өстәмә күрсәткеч: узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда тышкы сәүдә әйләнешенең үсеш темпы, процент | -24,9 | 31.12.2023 | -15,4 | 1,9 | 2,4 | 2,4 | 2,7 | 2,8 |
| 9. | Өстәмә күрсәткеч: узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда экспорт үсеше темпы, процент | -34,9 | 31.12.2023 | -14 | 2 | 2,4 | 2,4 | 2,8 | 2,8 |
| 10. | Өстәмә күрсәткеч: чит илләрдә эшләп торучы уртак сәнәгать мәйданчыклары саны, берәмлек | 2 | 31.12.2023 | 3 | 4 | 4 | 5 | 5 | 5 |

## IV. Экспортны үстерүнең төбәк программасы проектлары[1]

| Т/с | Бурыч исеме | Гамәлгә ашыру срогы | Аларга ирешүгә проектны гамәлгә ашыру юнәлдерелгән экспортны үстерү буенча төбәк программасының күрсәткечләре |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. «Татарстан Республикасында халыкара кооперация һәм экспортны үстерүнең системалы чаралары» проекты | | | |
| 1.1. | Татарстан Республикасында институциональ экспорт мохитен камилләштерү | 31.12.2030 | Төп күрсәткеч: чимал булмаган энергия булмаган экспортның реаль үсеше.<br>Төп күрсәткеч: сәнәгать тармаклары товарлары экспорты күләме. |

[1]Экспортны үстерүнең төбәк программасы проектлары паспортлары экспортны үстерүнең төбәк программасына 1 нче - 4 нче кушымталарда китерелгән.

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 1.2. | Татарстан Республикасында экспортны яклау инструментларын камилләштерү | 31.12.2030 | Төп күрсәткеч: агросәнәгать комплексы продукциясе экспорты күләме.<br>Өстәмә күрсәткеч: чимал булмаган энергия булмаган экспорт күләме.<br>Өстәмә күрсәткеч: кече һәм урта эшкуарлык субъектлары булган экспортерлар саны.<br>Өстәмә күрсәткеч: кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының чимал булмаган, энергия булмаган экспорты күләме.<br>Өстәмә күрсәткеч: Татарстан Республикасы экспортлый торган илләр саны |
| 2. «Чит илләрдә сәнәгать мәйданчыклары булдыру һәм үстерү» проекты | | | |
| 2.1. | Дус илләрнең чит ил базарларында катнашуны киңәйтү, сәнәгать кооперациясен киңәйтү | 31.12.2030 | Төп күрсәткеч: чимал булмаган энергия булмаган экспортның реаль үсеше.<br>Өстәмә күрсәткеч: Татарстан Республикасы экспортлый торган илләр саны.<br>Өстәмә күрсәткеч: чит илләрдә эшләп торучы уртак сәнәгать мәйданчыклары саны |
| 3. «Татарстан Республикасының вәкиллекләр системасын үстерү» проекты | | | |
| 3.1. | Дус илләр белән тотрыклы партнерлык системасын үстерү | 31.12.2030 | Төп күрсәткеч: чимал булмаган энергия булмаган экспортның реаль үсеше.<br>Өстәмә күрсәткеч: Татарстан Республикасы экспортлый торган илләр саны |
| 4. «Татарстан Республикасында агросәнәгать комплексы продукциясе экспоры» проекты | | | |
| 4.1. | АСК продукциясен экспортлауны хуплау өчен үтәли система булдыру һәм экспортны дус базарларга юнәлтүне хуплау инструментларын тәкъдим итү. | 31.12.2030 | Төп күрсәткеч: агросәнәгать комплексы продукциясе экспорты күләме |

## V. Экспортны үстерүнең төбәк программасын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү

| Т/с | Проектның исеме, экспортны үстерүнең төбәк программасы нәтиҗәләре һәм финанслау чыганаклары | Гамәлгә ашыру еллары буенча финанс белән тәэмин ителеш күләме, млн.сум | | | | | | Барлыгы, млн.сум |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел | 2029 ел | 2030 год | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| 1. | «Татарстан Республикасында халыкара кооперация һәм экспортны үстерүнең системалы чаралары» проекты | 217,2 | 151 | 166 | 183 | 200 | 220 | 1 137,2 |
| 1.1. | федераль бюджет (шул исәптән Татарстан Республикасы бюджетына бюджетара трансфертлар) | - | - | - | - | - | - | - |
| 1.2. | Россия Федерациясенең дәүләт бюджеттан тыш фондлары һәм аларның территориаль фондлары бюджетлары | - | - | - | - | - | - | - |
| 1.3. | Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджеты, шул исәптән:[1] | 79,2 | - | - | - | - | - | 79,2 |
| 1.3.1. | Татарстан Республикасы бюджеты | 79,2 | - | - | - | - | - | 79,2 |
| 1.3.1.1. | «Татарстан Республикасының Эшкуарлыкка ярдәм фонды» коммерциягә карамаган микрокредит компаниясенең Экспортка ярдәм үзәген финанслау | 79,2 | - | - | - | - | - | 79,2 |
| 1.3.2. | Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль берәмлекләр бюджетларына бюджетара трансфертлары | - | - | - | - | - | - | - |
| 1.3.3. | муниципаль берәмлекләр бюджетлары (Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджетара трансфертларны исәпкә алмыйча) | - | - | - | - | - | - | - |
| 1.4. | бюджеттан тыш чыганаклар | 138 | 151 | 166 | 183 | 200 | 220 | 1 058 |
| 1.4.1. | конгресс-күргәзмә эшчәнлеген финанслау | 138 | 151 | 166 | 183 | 200 | 220 | 1 058 |
| 2. | «Чит илләрдә сәнәгать мәйданчыклары булдыру һәм үстерү» проекты | - | - | - | - | - | - | - |
| 2.1. | федераль бюджет (шул исәптән Татарстан Республикасы бюджетына бюджетара трансфертлар) | - | - | - | - | - | - | - |
| 2.2. | Россия Федерациясенең дәүләт бюджеттан тыш фондлары һәм аларның территориаль фондлары бюджетлары | - | - | - | - | - | - | - |
| 2.3. | Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджеты, шул исәптән: | - | - | - | - | - | - | - |
| 2.3.1. | Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль берәмлекләр бюджетларына бюджетара трансфертлары | - | - | - | - | - | - | - |
| 2.3.2. | муниципаль берәмлекләр бюджетлары (Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджетара трансфертларны исәпкә алмыйча) | - | - | - | - | - | - | - |

[1]Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының икътисади үсеше һәм инновацион икътисады» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында" 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 25 июнь, 456 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) ярашлы рәвештә финанслау бүлеп бирелде.

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2.4. | бюджеттан тыш чыганаклар | - | - | - | - | - | - | - |
| 3. | «Татарстан Республикасының вәкиллекләр системасын үстерү» проекты[1] | 445 | 396 | 409 | - | - | - | 1 250 |
| 3.1. | федераль бюджет (шул исәптән Татарстан Республикасы бюджетына бюджетара трансфертлар) | - | - | - | - | - | - | - |
| 3.2. | Россия Федерациясенең дәүләт бюджеттан тыш фондлары һәм аларның территориаль фондлары бюджетлары | - | - | - | - | - | - | - |
| 3.3. | Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджеты, шул исәптән: | 445 | 396 | 409 | - | - | - | 1 250 |
| 3.3.1. | Татарстан Республикасы бюджеты | 445 | 396 | 409 | - | - | - | 1 250 |
| 3.3.1.1. | Татарстан Республикасының чит ил вәкиллекләре эшчәнлеген тәэмин итү | 445 | 396 | 409 | - | - | - | 1 250 |
| 3.3.2. | Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль берәмлекләр бюджетларына бюджетара трансфертлары | - | - | - | - | - | - | - |
| 3.3.3. | муниципаль берәмлекләр бюджетлары (Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджетара трансфертларны исәпкә алмыйча) | - | - | - | - | - | - | - |
| 3.4. | бюджеттан тыш чыганаклар | - | - | - | - | - | - | - |
| 4. | «Татарстан Республикасында агросәнәгать комплексы продукциясе экспоры» проекты | - | - | - | - | - | - | - |
| 4.1. | федераль бюджет (шул исәптән Татарстан Республикасы бюджетына бюджетара трансфертлар) | - | - | - | - | - | - | - |
| 4.2. | Россия Федерациясенең дәүләт бюджеттан тыш фондлары һәм аларның территориаль фондлары бюджетлары | - | - | - | - | - | - | - |
| 4.3. | Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджеты, шул исәптән: | - | - | - | - | - | - | - |
| 4.3.1. | Татарстан Республикасы бюджеты | - | - | - | - | - | - | - |
| 4.3.1.1. | Татарстан Республикасының чит ил вәкиллекләре эшчәнлеген тәэмин итү | - | - | - | - | - | - | - |
| 4.3.2. | Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль берәмлекләр бюджетларына бюджетара трансфертлары | - | - | - | - | - | - | - |
| 4.3.3. | муниципаль берәмлекләр бюджетлары (Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджетара трансфертларны исәпкә алмыйча) | - | - | - | - | - | - | - |
| 4.4. | бюджеттан тыш чыганаклар | - | - | - | - | - | - | - |

[1]«2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2024 елның 28 ноябрендәге 87-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә (2025 елның 18 июнендәге 33-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) финанслау бүлеп бирелде.

## VI. Экспортны үстерү төбәк программасын эшләү һәм гамәлгә ашыруда катнашучылар

| Т/с | Фамилиясе, исеме, атасының исеме | Вазыйфасы | Экспортны үстерү төбәк программасындагы роль |
|---|---|---|---|
| 1. | Коробченко Олег Владимирович | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры | экспортны үстерүнең төбәк программасы кураторы |
| 2. | Коробченко Олег Владимирович | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры | экспортны үстерүнең төбәк программасы җитәкчесе |
| 3. | Лернер Герман Янович | Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасары | экспортны үстерүнең төбәк программасы администраторы |
| 4. | Гайнуллов Рөстәм Рафаил улы | Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары | экспортны үстерүнең төбәк программасы катнашучысы |
| 5. | Галиева Рената Мөбарәк кызы | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының халыкара элемтәләрне үстерү бүлеге башлыгы | экспортны үстерүнең төбәк программасы катнашучысы |
| 6. | Гергерт Альбина Владимировна | «Татарстан Республикасының Эшкуарлыкка ярдәм фонды» коммерциягә карамаган микрокредит компаниясенең Экспортка ярдәм үзәге җитәкчесе | экспортны үстерүнең төбәк программасы катнашучысы |
| 7. | Иванов Сергей Евгеньевич | Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты рәисе | экспортны үстерүнең төбәк программасы катнашучысы |
| 8. | Кондратова Наталья Владимировна | Татарстан Республикасы икътисад министрының беренче урынбасары – Эшкуарлыкны үстерү департаменты директоры | экспортны үстерүнең төбәк программасы катнашучысы |
| 9. | Николаев Артур Сергеевич | «Татарстан Республикасының Сәүдә-сәнәгать палатасы» берлеге рәисенең беренче урынбасары | экспортны үстерүнең төбәк программасы катнашучысы |
| 10. | Сираев Илнар Рәшит улы | Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы башкарма комитетының эшмәкәрлекне үстерү һәм ярдәм итү идарәсе башлыгы | экспортны үстерүнең төбәк программасы катнашучысы |
| 11. | Хәйруллин Рамил Камил улы | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры урынбасары | экспортны үстерүнең төбәк программасы катнашучысы |
| 12. | Хәнифов Фәрит Мөдәррис улы | Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министры | экспортны үстерүнең төбәк программасы катнашучысы |

# VII. Төбәк экспорт стандарты 2.0 инструментларын кертү

| Бүлек | Инструментны кертү вакыты | Гамәлгә ашыру сыйфатнамәсе | Планлаштырылган чаралар |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| I. Татарстан Республикасында экспорт үсешен тәэмин итү платформасын булдыру | | | |
| 1. Татарстан Республикасында стратегик планлаштыру документларында экспортны, шул исәптән хезмәтләр экспортын үстерүне ныгыту | 28.12.2023 | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2030 елга кадәр Татарстан Республикасында тышкы икътисадый эшчәнлекне үстерү өчен уңайлы шартлар тәэмин итү стратегиясен раслау турында» 2023 ел, 28 декабрь, 1701 нче карары белән 2030 елга кадәр Татарстан Республикасында тышкы икътисадый эшчәнлекне үстерү өчен уңайлы шартлар тәэмин итү стратегиясе расланды (алга таба - Стратегия).<br>Россия Федерациясе Президентының «2030 елга кадәргә чорга һәм 2036 елга кадәр перспективада Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатлары турында» 2024 елның 7 маендагы 309 номерлы Указына нигезендә Стратегиягә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2030 елга кадәр Татарстан Республикасында экспорт эшчәнлеген үстерү өчен уңайлы шартлар тәэмин итү стратегиясен раслау турында» 2023 ел, 28 декабрь, 1701 нче карары белән расланган 2030 елга кадәр Татарстан Республикасында экспорт эшчәнлеген үстерү өчен уңайлы шартлар тәэмин итү стратегиясенә үзгәрешләр кертү хакында» 2024 ел, 02 ноябрь, 956 нчы карары белән үзгәрешләр кертелгән.<br>Стратегиягә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2030 елга кадәр Татарстан Республикасында экспорт эшчәнлеген үстерү өчен уңайлы шартлар тәэмин итү стратегиясен раслау турында» 2023 ел, 28 декабрь, 1701 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 ел, 28 июнь, 472 нче карары белән үзгәрешләр кертелгән. | Стратегияне гамәлгә ашыру |
| 2. Татарстан Республикасында чимал булмаган экспорт һәм хезмәтләр экспортын үстерү өчен җаваплы башкарма хакимият органын билгеләү | 03.03.2021 | Төбәк проектлары кураторлары, җитәкчеләре, администраторлары һәм аларны гамәлгә ашыру өчен җаваплы республика башкарма хакимият органнары исемлеге расланды (Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 27 апрелендәге 155 номерлы карары) | Татарстан Республикасында экспортка ярдәм итү һәм чимал булмаган экспортны үстерү чараларын координацияләү |
| 3. Татарстан Республикасында экспортны үстерү буенча идарә командасын форма- | 09.03.2022 (2030 елга кадәр ел саен) | Татарстан Республикасында идарә командасы булдырылды, аның составы һәм функцияләре Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 9 март, 464-б номерлы боерыгы белән расланды. | Идарә командасын «РЭҮ экспорт мәктәбе» АКБ ӨҺБО программасы |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| лаштыру һәм укыту (алга таба – идарә командасы) | | Идарә командасы «Россия экспорт үзәге» акционерлык җәмгыятенең экспорт мәктәбе» автоном коммерцияле булмаган өстәмә һөнәри белем бирү оешмасы программасы буенча укыту узды (алга таба – «РЭҮ экспорт мәктәбе» АКБ ӨҺБО) (даими нигездә) | буенча укытуны үткәрү. Төбәк экспорт стандарты 2.0 инструментын кертү |
| 4. Экспортны үстерү төбәк программасын эшләү һәм гамәлгә ашыру | 31.12.2024 | Экспортны үстерүнең төбәк программасы проекты төбәк программаларын эшләү буенча методик тәкъдимнәр таләпләренә туры китереп эшләнде | Экспортны үстерүнең төбәк программасын һәм төбәк программасында күрсәтелгән чаралар исемлеген гамәлгә ашыру |
| 5. Татарстан Республикасы югары вазыйфаи заты янында экспорт советы булдыру | 26.04.2018 | Татарстан Республикасы Экспорт советы 2018 елның 21 апрелендә оештырылды (Татарстан Республикасы Президентының 2018 елның 21 апрелендәге ПУ-326 номерлы Указы).<br>Татарстан Республикасы Экспорт советы утырышлары даими рәвештә Татарстан Республикасы Рәисе катнашында үткәрелә | Татарстан Республикасы Экспорт советы утырыш-ларын үткәрү (елга кимендә 4 тапкыр 2030 елга кадәр) |
| 6. Экспортка ярдәм итү үзәген булдыру һәм үстерү | 04.07.2012 | «Татарстан Республикасы эшмәкәрлеккә ярдәм фонды» коммерцияле булмаган микрокредит компаниясенең экспортка ярдәм үзәге 2012 елда булдырылды, Россия Федерациясе Икътисади үсеш министрлыгының барлык таләпләренә туры килүне раслау ел саен башкарыла. | «Татарстан Республикасы эшмәкәрлеккә ярдәм фонды» коммерцияле булмаган микрокредит компаниясенең экспортка ярдәм үзәген үстерү, «Кече һәм урта эшмәкәрлек һәм шәхси эшмәкәрлек инициатива-сына ярдәм» илкүләм проекты чараларын гамәлгә ашыру |
| 7. Татарстан Республика-сының чит ил базарларында катнашуын тәэмин итү | 31.12.2030 | Татарстан Республикасының чит ил дәүләтләре һәм чит ил дәүләтләренең административ-территориаль берәмлекләре белән хөкүмәтара килешүләр төзү эше алып барыла.<br>Ислам хезмәттәшлеге оешмасы илләре белән хезмәттәшлекне ныгыту дәвам итә.<br>Төрле секторларда мөнәсәбәтләр урнаштыру өчен актуаль илләр булып БДБ, Азия, Африка, Латин Америкасы, Якын Көнчыгыш илләре тора | Татарстан Республикасы-ның чит ил базарларында катнашуын киңәйтү |
| 8. Татарстан Республикасында югары белем бирү мәгариф оешмалары базасында тышкы | 12.02.2022 (даими нигездә 2030 | Укучыларны гамәли әзерләү турында килешүләр төзелгән:<br>Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы белән «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү | «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| икътисадый эшчәнлек өлкәсендә кадрлар әзерләү системасын булдыру һәм үстерү | елга кадәр) | оешмасы арасында;<br>Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы белән «ТИСБИ идарә университеты» югары белем бирү оешмасы арасында.<br>Татарстан Республикасының профильле белем бирү оешмаларында тышкы икътисадый эшчәнлек өлкәсендә расланган гамәли тәҗрибәгә ия экспертлар катнашында эшләнгән белем бирү программалары булуы тәэмин ителгән | югары белем бирү оешмасы белән укучыларның практикасын оештыру һәм үткәрү буенча хезмәттәшлек |
| 9. Татарстан Республикасында экспортчылар базасын һәм потенциаль экспортчылар базасын формалаштыру һәм анализлау, экспорт аудитын үткәрү | ел саен 2030 елга кадәр | Татарстан Республикасында экспортчылар базасы формалаштырылган, даими нигездә актуальләштерелә | Экспортчылар базасын киңәйтү һәм булган мәгълүматларны яңарту |
| II. Татарстан Республикасында экспорт эшчәнлегенә ярдәм итү өчен кирәкле чараларга керүне тәэмин итү | | | |
| 10. Экспортка юнәлтелгән эшмәкәрлек субъектларын экспорт эшчәнлеге нигезләренә өйрәтүне оештыру | ел саен 2030 елга кадәр | Татарстан Республикасында Татарстан Республикасының экспортка юнәлтелгән кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары өчен «РЭҮ экспорт мәктәбе» АКБ ӨҺБО семинарлары программасы гамәлгә ашырыла.<br>Системалы нигездә белем бирү чаралары гамәлгә ашырыла | Татарстан Республикасы экспортчылары өчен «РЭҮ экспорт мәктәбе» АКБ ӨҺБО программасы буенча семинарлар үткәрү |
| 11. Татарстан Республикасында теркәлгән эшмәкәрлек субъектларының потенциаль чит ил контрагентлары белән эшлекле элемтәләрен киңәйтү буенча чаралар комплексын оештыру | ел саен 2030 елга кадәр | Даими нигездә Татарстан Республикасы экспортчыларының Россиядә һәм чит илләрдә халыкара күргәзмәләрдә, бизнес-миссияләрдә катнашуы оештырыла | Татарстан Республикасы эшмәкәрлек субъектларының эшлекле элемтәләрен киңәйтү буенча чаралар комплексын гамәлгә ашыру |
| 12. Электрон сәүдә каналлары аша экспорт эшчәнлегенүстерү | ел саен 2030 елга кадәр | Электрон сәүдә мәйданчыклары белән вебинарлар үткәрелә, эшмәкәрләрне Россия һәм чит ил электрон сәүдә мәйданчыкларына чыгару оештырыла | Электрон сәүдә мәйданчыкларына чыгарылган эшмәкәрлек субъектлары санының артуы, товарлар һәм хезмәтләр сату вакытында мөһим инструмент буларак электрон сәүдә мәйданчыкларын популярлаштыру |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 13. Татарстан Республикасы территориясендә акселерация программаларын һәм экспорт үсешенең башка комплекслы инструментларын гамәлгә ашыру | 12.02.2015 (2030 елга кадәр ел саен) | Татарстан Республикасы предприятиеләре вәкилләренең акселерация программаларында катнашуы оештырыла:<br>«СКОЛ<br>КОВО» Мәскәү идарә мәктәбе тарафыннан гамәлгә ашырыла торган «Экспортер 2.0»;<br>«РЭҮ экспорт мәктәбе» АКБ ӨҺБО тарафыннан гамәлгә ашырыла торган «Экспортны үстерү акселераторы»;<br>«РЭҮ экспорт мәктәбе» АКБ ӨҺБО тарафыннан гамәлгә ашырыла торган «Экспорт форсажы».<br>Атна саен Татарстан Республикасының чит илләрдәге һәм Россия Федерациясе субъектларындагы вәкиллекләре катнашында видео-конференция режимында киңәшмәләр үткәрелә. Киңәшмәләрнең максаты - Татарстан Республикасының экспортка юнәлтелгән предприятиеләренә Татарстан Республикасы вәкиллекләре ягыннан да, уңышлы экспортчы предприятиеләр ягыннан да экспортка чыгуда кирәкле ярдәм күрсәтү, агымдагы мәсьәләләрне хәл итү | Татарстан Республикасы эшмәкәрләренең федераль экспорт акселерациясе программаларында катнашуын оештыру |
| III. Төбәкне чит ил базарларында алга җибәрү механизмнары һәм Татарстан Республикасында экспорт эшчәнлеген популярлаштыру | | | |
| 14. Татарстан Республика-сында икътисади актив халык һәм яшьләр арасында экспорт эшчәнлеген популярлаштыру механизмнарын булдыру һәм үстерү | ел саен 2030 елга кадәр | Төп социаль челтәрләрдә экспорт эшчәнлеген үстерүгә багышланган профильләр булдырылган.<br>«Ел экспортчысы» конкурсының төбәк этабы үткәрелә.<br>Ел саен массакүләм мәгълүмат чараларында системалы нигездә экспортчы образын популярлаштыруга һәм компанияләрне экспорт эшчәнлегенә җәлеп итүгә юнәлдерелгән реклама кампаниясе үткәрелә | Экспорт эшчәнлеген популярлаштыру инстру-ментларын киңәйтү |
| 15. Төбәк компанияләре продукциясен чит илдә алга җибәрү механизмнарын булдыру һәм үстерү | 11.12.2017 (2030 елга кадәр ел саен) | Республика компанияләренең бердәм республика стенды кысаларында конгресс-күргәзмә чараларында катнашуы оештырыла.<br>«Сәүдә вәкиле белән сәгать» форматында төбәк товарлары/хезмәтләре презентациясе үткәрелә | Төбәк компанияләре продукциясен чит илдә алга җибәрү механизм-нарын үстерү |